ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

06.12.2023 г. Казань № 399-13/т-2023

«БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыяте күрсәткән аэропорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларында, аэропортларында табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләре турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы һәм «Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең 2014 елның 31 октябрендәге 238-т/2 номерлы боерыгы белән расланган Аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә җыемнарны һәм тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу мәсьәләсе буенча методик күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 06.12.2023 № 52-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга 1-4 нче кушымталар нигезендә «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь чик тарифлар һәм җыемнар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь тарифларны (җыемнарны) билгеләү турында» 29.01.2016 № 7-1/т карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
06.12.2023 № 399-13/т-2023
карарына 1 нче кушымта

Аэропортта «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Россия кулланучылары өчен хезмәтләр күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик җыемнар

| Т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Җыем күләме |
|---|---|---|---|
| 1. | Очкычны күтәртү-төшерү өчен җыем | сум/т мвм | 965 |
| 2. | Авиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җыем | сум/т мвм | 645 |
| 3. | Эчке линияләрдә аэровокзал комплексы бирү өчен җыем | сум/пасс. | 123 |
| 4. | Халыкара линияләрдә аэровокзал комплексы бирү өчен җыем | сум/пасс. | 117 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
_______________ № _____________
карарына 2 нче кушымта

«БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Россия кулланучылары өчен хезмәтләр күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф күләме |
|---|---|---|---|
| 1. | Эчке һава линияләрендә пассажирларга хезмәт күрсәтү өчен тариф | сум/пасс. | 235 |
| 2. | Халыкара линияләрдә пассажирларга хезмәт күрсәтү өчен тариф | сум/пасс | 264 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
_______________ № _____________
карарына 3 нче кушымта

Аэропортта «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыяте тарафыннан Россия кулланучылары өчен хезмәтләр күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф күләме |
|---|---|---|---|
| 1. | Авиация ягулыгын саклау өчен тариф* | сум/т | 3 142 |
| 2. | Һава судноларына авиация ягулыгы салуны тәэмин иткән өчен тариф | сум/т | 2 509 |

* «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыятенә караган авиация ягулыгын саклау өчен тариф авиация ягулыгын сатканда кулланылмый

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
______________ № ____________
карарына 4 нче кушымта

Аэропортта «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыяте тарафыннан чит ил эксплуатантлары өчен хезмәтләр күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик җыемнар

| Т/с | Җыемның исеме | Үлчәү берәмлеге | Җыем күләме |
|---|---|---|---|
| 1. | Очкычны күтәртү-төшерү өчен җыем | сум/т мвм | 965 |
| 2. | Авиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җыем | сум/т мвм | 645 |
| 3. | Аэровокзал комплексын бирү өчен җыем | сум/пасс. | 117 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге